ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ МАРТ * 2020 * КАЗАН

3



Александр ШУЛЬПИНОВ

БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: СССР заманында буржуаз җәмгыятьтән бармак төртеп көлдек ласа. Сәгатен, "көнен" генә көтеп ятканнар икән – номенклатура чиновниклары бик кыска арада үзләре буржуйга әйләнеп бетте!

Алмаз Хәмзин: Буржуй – бүгенге түрә, ягъни акчасы күп кеше. Ә акчаның "күн" ягы һәм "иләк" ягы бар. Аны чөйсәң, ул – әле бер, әле икенче ягына әйләнә, ләкин һаман шул "акча" булып кала...

Р. Н.: Кеше туганда зынҗыр киеп тумый, җәмгыять аны үзе кидерә.

А. Х.: Безнең җәмгыять әле кигәнен дә салдыра.

Р. Н.: Ялагайның хәтта күләгәсе дә хуҗасына бил бөгәргә әзер.

А. Х.: Бездәге ялагайлык, күләгәсе тураеп, үзебезнең арт шәрифебезгә тибәрдәй дәрәҗәгә менде бугай инде. Оят!..

Р. Н.: "Салкын сугыш" конфликтларыннан котылуның бердәнбер юлы – Россия НАТО составына керергә тиеш.

А. Х.: Минемчә, хөкүмәт үз гражданнарына мәрхәмәтле, игелекле, гадел караш та булса, бернинди хәрби блокларга керү мөһим түгел.

Р. Н.: Тормыш тамчыламый, ул Идел кебек җәелеп ага.

А. Х.: Алай гына түгел, тормыш җиһан сыман кайный!

Р. Н.: Әдәбият-сәнгать дөньясында атлы арба алдында торасы урында – атлы арба артында барган кешеләрне күргәнең бармы синең?


А. Х. Бар. Җигүгә һәм җигелүгә карап, үзем.

Р. Н.: Рөхсәтсез бер агачны ексаң – штраф! Урманнарыбыз бер "рөхсәтсез" дөрләп яна... Кемгә штраф салырга?..

А. Х.: Безгә. Гади халык кесәсенә, пенсияңә, хезмәт хакыңа...

Р. Н.: Бәләкәй генә ядрә Сабантуй батырын егарга мөмкин.

А. Х. Ахмак кулындагы "ядерный чемодан" кнопкасы Җир шарын юкка чыгарырга күп сорамас.





ШОМБАЙ *болай диде...*

Хөрмәтле Чаян! Соңгы вакытта тагын глобаль җылыну куркынычы турында сүз кузгала башлады. Экология белгечләре, тиздән мәңгелек бозлыклар эреп, Җир шарының яртысын су басачак, һәм безгә яшәр урын калмаячак, дип белдерәләр. Икенчеләре исә – киресенчә, «глобаль җылыну» ул – кемнеңдер шәхси мәнфәгатьләрен тормышка ашыру өчен китереп чыгарылган уйдырма, дигән фикердә торалар...

Хат безнең Шомбай агабызда зур кызыксыну уятты.

– **Глобаль җылыну турында берни дә әйтә алмыйм,** – диде аксакалыбыз, – **әмма дөньяда глобаль җенләнү башланды инде...**

Алексей МАМАЕВ



Заман такмаклары

...Телевидениенең цифралысы
Шәп сурәттә сибә борчакны.
Уйланырга вакыт һәм теләк юк —
Ялганмы бу сүзләр йә хакмы.

Карыйбыз без шуны, авыз ачып
Аермыйча кара һәм акны.
Татлы җырлар
тыңлый-тыңлый шулай
Кашыйбыз без ачкан корсакны.

Гипермаркетлардан, җае чыккач,
Сирәк-мирәк ризык ташыйбыз.
Заманча бит — ай-яй, тәмле, диеп
"Доширак" һәм банан ашыйбыз.

Риза булып, кырыс хаким сипкән
Берән-сәрән җимне чукыйбыз.
Ач түгелбез — шуңа шөкер кылып,
Хөкүмәткә рәхмәт укыйбыз.

Кабул итәбез без уйланмыйча,
Хаклык итеп чеп-чи ялганны,
Хезмәт хакы диеп зур капчыкның
Тишегеннән төшеп калганны.

Ринат АБЗАЛОВ

Алмаз ХӘМЗИН

ИКЕ ТӨРЛЕ ЯШӘЕШ

Без яшәдек инде – булдыра алганча,
Сез яшисез хәзер типтереп – заманча!
Заманыгыз түгел безнеңчә – башкача,
Әллә нинди шунда: ни урысча-татарча...

Ринат МӘННАН

ЯШЬЛӘРГӘ КИҢӘШ

Машина сатып алганчы,
Бик нык уйла һәм аңла;
Көн дә кулга чүпрәк тотып,
Номерын сөртеп алырга
Син әзерме, аңгыра?!

Александр ШУЛЬПИНОВ



Энҗе тешләр һәм тирес

Ришвәтчелек, ягъни бүгенгечә әйтсәк – коррупция, илебездә гомер-гомердән килгән яман гадәт. Ул астан өскә кадәр, һәр юл чатында торган ЮХИДИ инспекторыннан башлап, югарыда утырган дәрәҗәле түрәләргә кадәр хас нәрсә. Һәр тәхеткә утырган яңа хаким эшчәнлеген нәкъ шуның белән көрәш игълан итүдән башлап җибәрә. Тик бу көрәшне, кызганыч, нәтиҗәле дип әйтеп булмый – ришвәтчелек, әкияттәге аждаһа кебек, бер киселгән баш урынына икене үстерә тора. Аның төрләре дә, кыяфәте дә һаман үзгәрә тора...

Дөньяда аждаһалар хөкем сөргән чаклардан бирле ришвәт күренеше шактый камилләште. Элеккеге конвертта бирелә торган гади ришвәткә яңа төрләр: «откат», үз кешеләргә тендерлар, бизнеста өлеш һәм башка «инновацияләр» өстәлде. Тик бу кыйммәтле әйберләр, ягъни «натура» белән ришвәт бирүнең кадерен бетермәде, ни дисәң дә, бәхет акчада гына түгел бит...

Новгород өлкәсенең Роспотребнадзор идарәсе җитәкчесе дә нәкъ шулай уйлаган, күрәсең. Ул ришвәтне барлыгы ярты миллион сумлык йорт җиһазлары һәм стоматология хезмәте хәлендә кабул иткән. Нәтиҗәдә, энҗе тешләр һәм йомшак диван иясе гаепләнүчеләр эскәмиясенә көчләп утырырга мәҗбүр булган. Тагын бер арт санын иркәләргә яратучы күрше Башкортстанның Благовар районында табылган. Андагы юл инспекциясе башлыгы «бүләк» сыйфатында офис кәнәфие алган...

Тик өстәлләр, теш пломбалары, йомшак кәнәфиләр – чиновник фантазиясе өчен чик түгел әле. Берничә ел элек Байкал аръягы Федераль миграция хезмәтен җитәкләүче ханым белән булган вакыйга бөтен илгә яңгырады. Легаль булмаган мигрантларны эшкә яллаган эшмәкәргә кагылмауны ул йөз тимер юл шпаласына бәяләгән иде. Шпалалар аңа ник кирәк булгандыр – билгесез. Бәлки, ул шәхси тимер юл төзү планлаштыргандыр?

Ришвәт алу төрләренең бай сандыгыннан тагын бер хәл. Берзаман Свердловск өлкәсендә ике юл инспекторы бер «салмыш» машина йөртүчене тоткарлыйлар. Аны җаваплылыкка тартып маташмыйлар, ә турыдан-туры... ломбардка алып китәләр. Автомобилен хокук сакчылары күзәтүе астында бичара анда 6 мең сумга сала. Олы юлның хуҗалары ул акчаны үзара бүлешәләр.

Ләкин бөтен гаишникларны да бер дәрәҗәдә комсыз дию дөрес булмас иде. Удмуртиядә ашханәдә эшләүче бер ханым машинада правасыз йөргән. Җәзадан котылыр өчен, ул үзен тоткарлаган инспекторга аны ашханәдә ел буе бушлай ашатырга тәкъдим иткән. Ләкин кырыс закон сакчысының йөрәгенә ашказаны аша юл салу барып чыкмаган: хатынны дәүләт хезмәткәренә ришвәт бирүдә гаепләгәннәр.

Чиләбе өлкәсендә кызыклы хәл булган. Анда Светлов авыл җирлеге башлыгы коммерция фирмасына экскаватор һәм биш җир участогы тапшырган. Юмартлыгы өчен шома башлык йорт хайваннарын ашату өчен 4 тонна ашлык калдыгы һәм өстәмә рәвештә судтан шартлы срок алган.

Әйтергә кирәк, ватаныбызда үрчегән ришвәтчеләрдән аларның чит илдәге тугандашлары да калышмый. Казакъстанда, мәсәлән, бер җирле хаким кирәкле имза өчен сыер тиресе алуда тотылган. Башлык урыныннан колак каккан, ә тиресне дәүләт файдасына конфискацияләгәннәр. Украинада ике инспектор юл кагыйдәләрен бозучыдан ике кап презерватив алганда капкан. Кытайда исә Цзянси провинциясенең вице-губернаторы «мәсьәләләрне» файдалануга бирелгән «мәхәббәт күбәләкләре» өчен хәл иткән һәм шуның өчен төрмәгә эләккән. Ә Кытай армиясенең тыл буенча Баш идарәсе башлыгы урынбасарына алтын коелмалары төялгән машина өчен гомере белән хушлашырга туры килгән...

Һәм сүзебезне классикадан алынган мисал белән тәмамлыйк. Новосибирск каласында, нәкъ Гоголь пьесасындагы кебек, бер җирле «Ляпкин-Тяпкин» ришвәтне көчекләр белән алырга булган. Бүләк сыйфатында ул 30 мең сумлык Йоркшир терьеры кабул иткән. Акча түгел бит дип уйлаган, күрәсең...

Илгиз ИСКӘНДӘРЕВ



әйтсәләр әйтәләр...



Минем алдымда ике юл ята иде. Беренчесе – халкымны шәрә җирдә калдырып, тормышымны урлашуга багышлау, дусларымны һәм туганнарымны «Форбс» исемлегенә кертү. Икенчесе – халкыма хезмәт итү һәм илемне дөньяның иң бай илләр исемлегенә кертү. Мин икенче юлны сайладым...

Ли КУАН Ю,
Сингапур икътисадый могҗиза авторы.

Вячеслав ШИЛОВ









• • •

Хатыны бәбиләгәч, ире бала тудыру йортына килә. Янына шәфкать туташы чыга да:

– Сезнең малай, 3700... – ди.

Ир, акчасын санап:

– Карале, әллә ни кыйбат түгел икән! – дип гаҗәпкә кала.

• • •

Хатын-кыз логикасы:

– Ни өчен – ни өчен? Чөнки мин шулай уйлыйм... ә ни өчен шулай уйлыйм, чөнки анысын уйламадым әле...

• • •

– Сезнең ирегез кайда эшли?

– Өченче ай инде аракы заводында.

– Ничек соң, ошыймы аңа анда?

– Белмим. Аның әле кайтып күренгәне юк.

• • •

– Ялга чыгу графигы төзеп утырам, сиңа нинди хәреф белән башланган ай кирәк?

– "И" хәрефенә.

– Яхшы, инварда чыгарсың.

• • •

Немец кибетендә уенчык югалган. Шундук ревизия ясый башлаганнар, тикшерүләр... Бездә 100 гектар күркәм урман юкка чыккан. Сәбәбен күрсәткән аңлатмада бер генә сүз язылган: "Кондызлар!.."

• • •

Хатыныгыз сайлаган нәрсәдән беркайчан да көлмәгез... Чөнки сез – шулай ук ул сайлаган нәрсә.

• • •

1917 елдан бирле халык хокук таләп итә. Әлегә ул 2% кына үтәлгән.

• • •

Суыткыч буш булса да, көненә икеөч мәртәбә ачып карауны үти ул, әле күбрәк тә булмаса.

• • •

Мин ят кеше тормышына гына психолог. Үземнекендә – мин псих.

• • •

"Ура-а!!! Каникуллар!!!" – дип сөенде әти-әниләр, шатлыкларын яшермичә, көндәлек дәфтәрләрен болгый-болгый сикергәләп.

РИШВӘТ АЛМАГАН ПОЛИЦЕЙСКИЙ

1836 елның августында Казанга Николай I галиҗәнаплары килеп төшә. Императорны яраннары белән губернатор С. Стрекалов каршылый. Алар арасында каланың 1 нче полиция бүлеге приставы Шаһиәхмәт ибн Мөхәммәт, ягъни ул чактагыдай «русчалаштырып» әйткәндә, Алексей Михайлович Алкин да була. Приставны император белән «юлбасарларны һәм ут төртүчеләрне» калтыратып тотучы дип таныштыралар. Патша тырыш чиновникка рәхмәт белдерә, һәм җинаятьчелекне тулысынча бетерү эшендә аңа уңышлар тели.

Ул вакытта Казанда, башка зур шәһәрләрдәге кебек, кояш бату белән урамнарда йөрү куркыныч була, ә талаулар һәм үтерүләр гадәти нәрсә булып саналган. «Бәйдән ычкынган» җинаятьчеләргә каршы чара таба алмыйча, губерна җитәкчеләре хәтта Оренбург һәм Урал гаскәрләренең махсус казак командаларына мөрәҗәгать итәләр, ә Казанда – Идел буенда талаулар белән көрәшү өчен махсус флотилия тоталар.

Шаһиәхмәт Алкин табигый акылы, тирән белеме, татар һәм рус телләрен яхшы белүе белән аерылып торган. Шулай ук ул батыр һәм көчле, бик кыю булып танылган. Күп тапкырлар үзе җинаятьчеләрне тоткарлауда катнашкан. Казан үзәгендә булган күпсанлы талауларны ачканы өчен Алкин 1833 елда алтын сәгать белән бүләкләнә. Ә 40 нчы еллар башында яманатлары чыккан юлбасарлар Чайкин һәм Быковны эзләгәндә үзен яхшы яктан күрсәтә. Аларны кулга алу һәм Арча кырында халык алдында җәзалау казанлылар тарафыннан җиңеләю белән кабул ителә.

Пристав Алкинның ихтирамга лаек бер «сәер» сыйфаты була: ул беркайчан да ришвәт алмый. Ә ул вакытлар, хәзерге сүзләр белән әйткәндә, «коррупция»нең чәчәк аткан чагы була. Берзаман император Николай, дәүләттәге хәлләр белән танышканнан соң: «Бу илдә бер генә кеше урлашмый бугай, һәм бу кеше – мин», – дип әйтеп куйган, имеш. Һәм без, казанлылар, моңа полицмейстер Алкинны да өстәп куя алабыз.

Аның тормыш юлында тагын бер «сәерлеге» игътибарга лаек: ул мөселмалыктан баш тартып, христиан динен кабул итү тәкъдимнәрен күп тапкырлар кире кага. Аңа карата ихтирам шундый дәрәҗәдә була ки, хакимият аның эш урынында таһарәт алу өчен комган тотуы көн саен намаз укуына һәм дә игътибар итми.

Полицмейстер Алкин Казан тарихына 1917 елга кадәр чукынмаган килеш җәмгыятьтә шундый югары дәрәҗәгә ирешкән кеше булып кергән. Атаклы дин әһеле һәм мәгърифәтче Мәрҗани аны бөтен Казанны калтыратып тоткан кеше дип атаган. Әйтергә кирәк, мәгърифәтченең язмышында да Алкин әһәмиятле роль уйнаган. Мәрҗанинең муллалар белән чираттагы каршы тору вакытында ул аны эзәрлекләүләрдән һәм урынын югалтудан коткарып калган.

1859 елда, 52 яшендә, көтмәгәндә Алкин отставкага рапорт бирә. Үгетләүләргә карамастан, ул урыныннан баш тарта, һәм дәүләт тарафыннан бирелгән 285 сум көмеш күләмендә «тулы пансион»га күчә. Вакытының күп өлешен Алкин үзенең зур гаиләсе белән Мамадыш өязендәге тыйнак утарында уздыра. Ришвәт алмаган полицейский 1875 елда вафат була һәм Яңа Татар бистәсендә «Яңа зират»та җирләнә.


Виктор ФЁДОРОВ




Виктор БОГОРАД



Виктор БОГОРАД



Виталий ПОДВИЦКИЙ



БЕЛДЕРҮ!

9 марттан Халыкара хатын-кызлар көненнән зыян күргән ир-атлар өчен реабилитация үзәге эшли башлый. Үзәкнең адресы: «Көпчәк» гараж кооперативы, 5 нче блок. Үзәккә ярдәм сорап килүчеләргә тулы һәм сыйфатлы хезмәт күрсәтелә: күпьеллык стажлы, тәҗрибәле психолог Сәмигулыч консультацияләре, мангал, киптерелгән балык, сыра запаслары, өстәл уеннары һәм ВАЗ-2101 уен конструкторы.

Василий АЛЕКСАНДРОВ





ЧЫНГА АШМАС ПЛАННАР

Кадерле "Чаян"! Элек почтаның бик әкрен эшләве турында шаяртырга ярата иде халык. Янәсе, күгәрек сыр, уксус, киптерелгән җимешләр – почта эшенең әкрен эшләү нәтиҗәсеннән барлыкка килгән. Заманага яраклашып, инде почтадан җәһәт кенә макарон, кер юа торган порошок, урын-җир әсбаплары һәм башка нәрсәләр дә алырга була. Тиздән дару һәм спиртлы эчемлекләр дә булачак дигән имеш-мимеш йөри сатуда...

Болар барысы да шәп шәбен, ә менә газета-журналлар тарату нинди хәлдә икән? Авыл җирлегендә, белүемчә, басма газета-журналлар соңарып, атнага бер тапкыр гына колачлап килә.

Авыл халкы зарланып та карады, шулхәтле әз зарплатага кемдер килгәненә сөенегез әле дигән җавапны гына ишетә алар. Дөрестән дә, әлеге хезмәт хакына кар ерып, яңгыр астында пенсия, җыелып яткан газета-журналлар һәм башка кирәк-ярак товарлар таратучы сирәктер...

Ишетүемчә, тиздән почта хезмәткәрләрен өйләрендә фельдшер ярдәме күрсәтергә өйрәтмәкчеләр икән. Почта хәбәрен озаклап көтеп тә ала алмаган халыкка беренче ярдәм күрсәтү уңаеннан чыгып эшләнгән күрәсең бу...

А. ГАБДУЛЛИН

ЧАЛЛЫ

АКЛАНМАГАН ӨМЕТЛӘР

Хөрмәтле редакция! Белгәнебезчә, вәгъдәне өч ел көтәсе, анысы да әле бәхет елмайса гына... Киров районында урнашкан "Заречье" балалар үзәген төзеп бетереп тапшыру көннәре әллә кайчан узды инде. 2007 елда бинаны яраксыз дип табып, яңа бина төзүгә керештеләр. Ләкин моңа ирешергә бөтен дөньяга китереп суккан кризис комачаулады.

Еллар үтә, үзәк кулдан-кулга, бер урыннан икенче урынга күчеп яши бирә. Ниһаять, Окольный урамыннан иске бер бина бүлеп бирделәр. Дүрт мең бала өчен ул бик кысан булып чыкты. Балалар, укытучылар һәм әти-әниләр бик зарыгып яңа бина көтәләр. Күптән түгел, озак төзелгән бинаны сүтеп, торак йортлары һәм яңа сату-алу комплексы төзеләчәген белдек. Моны исә өч ел түгел, өч көндә төзеп бетерәчәкләр...

"Заречье" балалар үзәгенең әти-әниләре.

КАЗАН

Александр АЛЁШИН



Дамир МОРТАЗИН

ЮКТАН ДА СӨЕНЕП ЯШИБЕЗ

Рәис, яңа гына сатып алган Лада-Вестасын кабызып, ашыкмый гына урыныннан кузгалды. Рәхәт тә инде шундый чакта, күңелле дә. Әле бит янәшәсендә чибәр генә хатыны да утыра, илле яшь дип тә әйтмәссең үзенә – кырыклар чамасы гына. Ул, авторадиодан Салаватның җаннарны эретердәй җырын тапты да, шуңа кушылып җырлап ук җибәрде...

Урам чатында кызыл ут янган светофорга туктарга туры килде, һәм ул үз ягындагы тәрәзәгә карады. Сул ягында, чинап, алагаем кара джип калыкты. Руль артында пеләш башлы абзый, ә янәшәсендә – гаҗәеп гүзәл кыз. "Мөгаен, этиседер..." – дип уйлап куйды Рәис. "Ну урлап та караган икән кабахәт, менә хәзер мактанып йөри", – дигән ачуын өстәде. Шундук кәефе төште. Япон джибы безнең Веста түгел шул! Кырыендагы кыз да... кызы түгелдер әле. Ул хатынына карады да авыр сулап алды...

Икенче урам кисешкәнчегә хәтле һаман сөмсере коелып барды. Светофорга туктагач, янына менә-менә таралырга торган һәм дә кара төтен чыгарып, кадеми заманындагы "Москвич" килеп басты. Руль артында, сеңеп, тончыгып беткән ир утырган. Кырыенда – алагаем зур борынлы, усал чырайлы апа. Рәис, иң өсте белән хатынына төртеп елмайды да, җайлап кына, егетләрчә кыланып, газ педаленә басты.

Үзенең йортына килеп җитәрәк, халык күплегеннән корсагы җиргә тиеп баручы автобус ишегеннән күршесе Гомәр ишелеп төшкәнне күрде. Ул бөгәрләнгән, йомарланган, тетелгән бәрәңге капчыгын хәтерләтә иде. Рәис фыркылдап көлде дә, шатланып бот чабып куйды. Кәефенең кинәт күтәрелеп киткәнен күрсәгез!.. Менә шулай, кешенең юктан да күңеле була бит!

Александр БРЮХАНОВ

ДЕТЕКТОР

– Без бөтен эшкә кабул ителүчеләрне ялган детекторында тикшерәбез. Сез бу турыда беләсезме?
– Әлбәттә...
– Димәк, моны сезгә дә үтәргә туры киләчәк.
– Кирәк икән, үтәрмен...
– Алайса тоташтырабыз...
– Мин әзер.
– Сез безгә нинди максат белән киләсез?
– Үземне тулысынча милли проектларны тормышка ашыру һәм халыкның яшәү дәрәҗәсен күтәрү өчен!
– Сез эшкә шәхси файда алыр өчен урнашасызмы?
– Юк ла инде, нинди файда ди ул... Минем бөтен нәрсәм дә бар ич...
– Каян җыелган? Турыдан-туры җавап бирегез!
– Яшереп торасы да юк! Хатыным – уңышлы бизнесмен, кайнанам – өченче буын финансист, әбием – талантлы менеджер, ә бабам байлык калдырып китте...
– Сез акча яратасызмы?
– Куралмыйм! Бөтен бәла, тынгысызлык шул акчадан! Төннәр буе йокламыйча, салымнардан ничек котылу, декларацияне ничек үзгәртеп бирү турында баш катырып ятасың... Булганыннан колак кагуың да бик мөмкин бит...
– Сезнең күчемсез милкегез йә чит ил банкларында счётларыгыз бармы?..
– Ни сөйлисез сез? Мин кайда яшәгәнемне беләм бит. Бөтен милкем – йөри алмыйча түшәктә ятучы әбием...
– Әбиегез – ул теге талантлы менеджермы?
– Әйе, ул өйдә эшли... Компьютер аша...
– Сезнең законнан яшерердәй нәрсәгез бармы?
– Сез, нәрсә? Безнең законнар кеше мәнфәгатьләрен саклау өчен бит, җәза бирү өчен түгел...
– Булды! Тикшерү тәмам. Без сезне алабыз, безгә нәкъ сезнең кебекләр кирәк...
– Мин бөтен сорауларга да тиешенчә җавап бирдемме соң?
– Ничек дип әйтергә инде... Тик сез үзегезгә шулхәтле ышанып алдадыгыз!!
– Сездә өмет бар дип уйлыйм...



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Алмаз ХӘМЗИН

ТӘКЪДИМ ИТӘМ

Депутатлар,
Намус, вөҗдан, дөреслек дигән
Мәгънәләр бармы сездә?
Тәкъдим итәм:
Кертергә бу төшенчәләрне
Конституциябезгә!

Түрәләргә
Талаганнарын кайтарырга
Һәм халыкка бүләргә!
Тәкъдим итәм:
Кайсы илдә акча саклый ул –
Менә шунда сөрергә!

Эшчеләргә,
Завод-фабрикаларны кабат
Үзләренә алырга.
Тәкъдим итәм:
Шунсыз илсез дә калабыз бит,
Ышансаң бу байларга.

Крәстияннар,
Уяныгыз, йоклап ятмагыз,
Калгансыз ич сыерсыз.
Тәкъдим итәм:
Фетнә күтәрми-нитми генә
Фермер булып куегыз!

Зыялылар,
Йөрмәгез мескенләнеп сорап
Гонорар түләүләрен.
Тәкъдим итәм:
Җәберләүләргә закон ясап,
Гафу үтенүләрен.

Хәерчеләр,
Сезгә дә мөрәҗәгать итәм –
Сез дә безнең кешеләр!
Тәкъдим итәм:
Бергәләшеп, иң гадел дәүләт
Без төзәргә тиешләр!



Сергей АНДРИАНОВ

Абау!

ШӘРАБ БЕЛӘН ГАЕП ЙОЛУ

Казан хакимияте гаепләнүче гражданнар өчен эш урыннары исемлеге төзегән. Заводлар, автотранспорт предприятиеләре һәм коммуналь оешмалардан башка, анда көтмәгәндә М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры һәм шәраб заводы да эләккән. Ләкин удар хезмәт белән җәмгыять алдындагы гаебеңне йолу бәхете бөтен кешегә дә тәтеми, ул судка кадәр беркайда да эшләмәгән гражданнарга гына кагыла.

РУЛЬДӘ... ШАШКА ТУРНИРЫ

Татарстанның юл инспекциясен казанлыларның ничек итеп машина йөртүләре һәм аларның түбән культурасы чынлап борчый башлаган. Күпләр үзләрен юлда тәртипсез тота, тизлекне арттыра, җәяүлеләргә юл бирми, каешны эләктермиләр һәм юл хәрәкәте кагыйдәләрен боза икән. Мисал сыйфатында, инспекторлар күптән түгел булган аварияне китергәннәр. Анда ике кеше һәлак булган. Каешны эләктермәгән машина йөртүче һәм пассажир хәрәкәт вакытында шашка уйнаганнар, ә салонда иминлек каешлары, гомумән, булмаган.

ГАИЛӘ БИЗНЕСЫ

Чаллы суды Пётр Богданов атлы бәндәгә карата хөкем карары чыгарган. Бергә яшәүче хатыны Алсу Әхмәдиева белән берлектә иҗтимагый челтәрләрдә татлы итеп вакыт уздырырга теләүчеләрне табып, саунада очрашу турында сүз куешканнар. Очрашу видеога төшерелгән. Аннан соң кайнар сөю корбаннарыннан видеоязманы дөньяга чыгармау өчен акча таләп иткәннәр. "Бизнесмен" үзе – дүрт, ә мәгъшукасы ике елга утырган.

МӨГЕЗЛЕ ЯЛГАН

Чаллыдагы "КА" исемле сәүдә йорты Казакъстанның крестьян хуҗалыкларын төп башына утырткан. Казакъ фермерлары компания белән 116,6 миллион сумга 1187 баш герефорд токымлы сыер сатып алу турында килешенү төзегәннәр һәм акча күчергәннәр. Ләкин мөгезле терлекләр Казакъстан далаларына барып җитмәгән. Хәзер партнёрларына "мөгез куйган" татарстанлылар белән тикшерү органнары шөгыльләнә.

КАРА КӨЧЛӘР ТӘЭСИРЕ

Әлмәттә яшәүче бер егет Уфага сөйгән кызы янына кунакка бара. Кире кайтышлый ул, юлы уңышлы бусын өчен, чиркәүгә кереп шәм куеп чыгарга була. Әмма гыйбадәтханәдә ул көтмәгәндә "кара көчләр" тәэсиренә эләгә. Һәм чиркәү кибетенең пыяла киштәсен ватып, андагы алтын-көмеш әйберләрне эләктереп, табан ялтырата. Соңыннан полициядә ул бу хәлне кара көчләргә сылтарга маташа – имеш, затлы әйберләр аңа үзләре "ябышып" чыкканнар икән. Фанилык кануннары буенча эш итәргә күнеккән полицейскийлар бу әкиятләргә ышанмыйлар һәм чиркәү карагына каршы җинаять эше кузгаталар.









Бу көннәрдә күренекле шагыйрь, бик күп дәрәҗәле әдәби премияләр лауреаты Рашат Низамига 70 яшь тулды. Аны укучыларыбыз "Чаян" битләрендә басылган үткен фикерләре аша яхшы беләләр. Әлбәттә, без, редакция хезмәткәрләре, әдибебезне журналыбызда яңа шигырьләрен бастырып, чын күңелдән олы юбилее белән котлыйбыз һәм "Чаян"ны укучылар тарафыннан да сәламлибез.

Безнең Рашат бигрәк тату
"Чаян" белән.
"Чаян" да бит аңа карый –
Дәрәҗәдән!

Коеп куйган шагыйрь дисәк,
Үпкәләмәс.
Сатирик дип үстерсәк тә,
Мишәйт итмәс!

Һәр санында журналыбыз
Шигырь баса.
"Низами"лар күп түгел шул,
Бездә, ласа!

Япь-яшь килеш җитмеш тулган
Низамига!
Йөз тулса да аның кебек
Берәү дә язмас һәм
Язалмый да!

САЙЛАУ АЛДЫ ТАКМАЗАСЫ

Сайлау үзе шактый кызык нәрсә:
Кем икәнен кемнең белмисең.
Тавышыңны ләкин сал тартмага,
Синең тавыш чөнки үлемсез!
Бер атнадан, бәлки, өч атнадан
Кемнең кем икәнен күрерсез...
Арысланнан карга килеп чыкса,
Менә монысы булыр күңелсез...

ИСКЕ НИГЕЗ

Таралып беткән туганнар,
Ярылмый ята тумраннар.
Утын тукмагы картайган –
Тәмам-тәмам муртайган...

ХАЛӘТ

Ялган белән тулы бу заманда
Күңелне бер килә җиллəтәсе!
Урманнарга керсәң дә бит чорный
Черкиләрнең соры җилпәзәсе...

ТАНЫШУ

Казан шәһәренең бер паркында егет белән кыз танышалар. Бермәлне кыз әйтеп куя:

– Минем абый – язучы Рашат Низами.

Кияү буласы егет тә югалып калмый, сүзен өздереп әйтә:

– Ә минем абый – Камал театры артисты Хәлим Җәләй.

Икесе дә канәгать елмая.

ҮРТӘШҮ

(мәсәл)

Шулай бервакыт чыпчык белән саескан очрашкан. Юкны бар итеп, үртәшергә керешкән, ди, болар.

– Син кешеләр янына якын килергә дә куркасың бит, – ди икән чыпчык, үзенчә гайрәт чәчеп.

– Әй мактанчык! Син бит күрер күзгә бигрәкләр дә почык, бәләкәй. Кешеләр сине абайлап та өлгерми, – дип мыскыллаган аны читән башындагы саескан.

– Ә синең күзең карак, телең әләкче, – дип хурлаган аны чыпчык.

Шул вакыт биек-биектә, аларның баш очындарак ялгыз Тилгән пәйда булган.

Аның җиргә уктай ташлануы булган, чыпчык – үзенең куышына, ә саескан исә абзар-кура ышыгына кереп качкан!

Бу мәсәлнең морале: Кояш астында һәр кошның үз урыны, үз биеклеге бар.

КЕМ ҖИҢҮЧЕ?

Шахмат уйнарга керешкән
коньяк белән аракы.
Коньяк әнә, хәйлә корып,
"Мат" куймакчы, сабакы!

Тактадагы фигуралар
Рюмкалар вә ыстакан.
Судьялыкны алып бара
Вәли белән Ычтапан.

"Кем җиңәчәк?" – дия-дия
Шаулашалар гөр килеп.
Өстәл тирәсендә аңкый
Хәмер исе, бөркелеп.

Маңгайга-маңгай чәкәшеп,
Бил алыша шешәләр.
Ә ирләрме? Сәрхушләнеп
Билдән авып төшәләр.

...Аркага салды ирләрне
Коньяк белән аракы.
Бу бәйгедә җиңүчеләр
Шулар булды, сабакы!

ГОМЕР АГАЧЫ

Яшьлегемнең агачында –
Яшькелт алмалар иде.
Картлыгымның агачында
Сары яфраклар иле...

ФАНИЛЫК


Фанилыкта – һәркем бер данә,
"Мин!.." дип аваз сала бүдәнә.
Яшәүләрнең көмеш әҗере
Доллар белән хәзер түләнә.


ЕРАКЛАШУ

Бер-береннән ераклашып яши
Күрше-күлән, туган-тумача.
Тимер ишек белән уратылдык,
Ишекләрне хәзер кем ача?..

БУЛСА КЕШЕ...

Булса кеше – матди байлык корты,
Җитми кала акыл чүт кенә:
Туган тел һәм милли хәзинәләр,
Рухи байлык аңа чүп кенә...









Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Бик күп кешеләр сүздән эшкә күчкән чорда хәбәрсез югалалар.

• • •

Белдерү: "Тәҗрибәле күрәзәче лайклар буенча кем, кайда, кем белән, кайчан һәм ничаклы булдыра алганын сөйләп бирә".

• • •

– Сез шундый тыныч. Сез нәрсә кабул итәсез?

– Бөтенесен, ничек бар.

• • •

Ханымнар, яшь сөяркәләр белән мавыкмагыз! Мин бүген үземнекенә төне буе кемнәр пионерлар булган һәм диафильмнар нәрсә икәнен аңлатып чыктым...

• • •

Кунакханәләрдә фенның розеткадан тартып чыгарып булмаганын, ә элгечләрне шкафка беркетелгәнен күргәч, күңелгә һәрвакыт шундый уй килә: "Алар мине сәяхәтләргә отверткасыз чыга дип уйлыйлар микәнни?"

• • •

Хатын-кызны аңлау бик җиңел: ул кытай телендәге квант физикасының ачык китабы шикелле.

• • •

Интернет уйлап табылганчыга хәтле, кайчагында чамалап сөйләшмәгән кешеләрнең чырайларына менеп төшкәләгәннәр – онытканбыз шуны.

• • •

Ябалаклар – бик зирәк кошлар. Кайчан да булса сезнең кредит алган ябалакны күргәнегез бармы? Шул-шул...

• • •

Әгәр дә сезнең чаңгыда таудан шуу курортында төшкән фотосурәтегез булмаса, кайгырмагыз – ят кешеләрнекен кулланыгыз, сезне барыбер берәү дә танымаячак, чөнки сез шлемда һәм битлектә.

• • •

Унитазда утырып, газета укыган чакта сез теләсә нинди яңалыкка әзер.

Абау!

КАДРЛАР БӨТЕНЕСЕН ЭШЛИ

Якутиянең Хангаласс районы житәкчесенең беренче урынбасары Федор Борисов киңәшмәдә көтелмәгән үзгәрешләр турында сөйләгән. Түрә уйлавынча, аның сәламәтлек, озак яшәү һәм шулай ук рухи үсеш буенча урынбасарлары булырга тиеш. Ул тагын Дәүләт Аппаратында рәссамнар, язучылар, спорт һәм туган якны өйрәнү буенча киңәшчеләр күрергә теләгән. Борисов гади халыкны да онытмаган, халыкның лаеклы тормышы буенча урынбасар булдыруны планга керткән. Икътисад һәм финансларны ул үз өстендә калдырган. Район халкы мондый революцияне хупламаган. Алар урынбасарлар урынына бер шаман алырга киңәш биргәннәр.

ИНТИМ РАКУРС

Калининградның 4 нче бала табу йортының УЗИ кабинетына, пациенткалар ята торган кушетка каршысына камера куйганнар. Ачулары кабарган хатын-кызларга баш табиб, видеога төшерү шәхси эш түгел, дип белдергән. Видео язма күрсәтелгән хезмәтнең сыйфатын контрольдә тотарга, җиһазның саклыгын һәм коррупцион куркынычсызлыкны тәэмин итәр өчен куелган. Бу кызыклы язмаларны карарга баш табибның үзенең, аның берничә урынбасары һәм система администраторының мөмкинлеге бар икән.

КЫЮ КАРАР

Ульяновск өлкәсенең Теренгульск район советы депутатлары Лысогорск поселогының проблемаларын гадәти булмаган ысул белән игътибар җәлеп итәргә карар кылганнар. Берничә ел элек поселокта льготалы кешеләргә җир өләшкәннәр, тик төзелә торган йортларга ут, газ һәм су кертмәгәннәр. Түрәләргә җиткереп булмагач, депутатлар игътибарларын башка ысул – поселокның урам исемнәре белән җәлеп итәргә булганнар. Хәзер анда Сталин, Ветераннар, Җиңүгә – 75 ел, Путин урамнары барлыкка килгән. Халык сайлаган кешеләр өметләнүенчә, мондый кычкырып тора торган исемле урамнарның көенечле хәлдә булуы түрәләрне бераз кузгатып җибәрергә тиеш.

ӘҺӘМИЯТЛЕ КҮЛӘМ

Саратовның күп фатирлы йортларында ваннаның озынлыгын үлчәү турында белдерүләр барлыкка килгән. Коммуналь хезмәткәрләр уйлавынча, бу процедура (ваннаның озынлыгы 1,3 м дан 1,5 м га хәтле һәм озынрагы) кайнар суның тотылышының нормативын дөрес итеп санарга ярдәм итәчәк һәм тарифларны яңабаштан карарга мөмкинчелек бирәчәк. Ванналарның хуҗалары моңа саклык белән карый. Ваннаның озынлыгыннан башка аның биеклеге һәм киңлеге бар бит әле. Һәм бу процесс унитаз һәм раковиналарга да күчәргә мөмкин.





ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Аның көлмәгә артык соң башлана һәм бик иртә бетә иде.

Хатын-кыз нәфрәте – юнәлешен алыштырган сөю ул.

Намуслы хатыннар эшләнмичә калган хаталары өчен үзүзләрен гафу итә алмыйлар.

Ир кеше һәрвакыт хатын-кызның кулын үбәргә тиеш. Нәрсәдән булса да башларга кирәк бит.

Хатыныңа баш булыр өчен аңа бик еш буйсына белергә кирәк.

Хатынны үзгәртер өчен, аның әбисеннән башларга кирәк. Өйләнгән ирләр беркайчан да акылларын җуймыйлар – чөнки аларга өйләнү турында баш ватарга кирәк түгел.



Сергей АНДРИАНОВ





Игорь КИЙКО

• • •

Табиб бүлмәсенә скелет килеп керә.

Табиб:

– Менә, һәрвакыт шулай! Сузып йөриләр-йөриләр дә, аннан соң гына дәваланырга киләләр...

• • •

Доктор, күзем начарланды, ерактагы әйберләрне күрмим...

– Тәрәзә янына килегез әле. Нәрсә күрәсез?

– Кояшны күрәм.

– Шулай булгач? Кояштан да ерак нәрсә күрмәкче буласызмы тагын?



Валерий ТАРАСЕНКО

Василий АЛЕКСАНДРОВ





Муса ҖӘЛИЛ

ХӘДИЧӘ

Күрше кызы Хәдичә,
Шулай гадәттәгечә,
Озак йөреп бакчада,
Кичегеп кайтты кичә.

Каравылчы карт аның
Ишетмәгән кайтканын.
Шуңар күрә ачмаган
Хәдичәгә капканы.

Капкада тимер йозак,
Хәдичә көткән озак.
Тышта кунып булмый бит,
Булса да гәрчә йөз ак.

Ахры кызга уй керә,
Төнлә белән кем күрә?
Күп тикшерми Хәдичә,
Койма аша сикерә.

Кайтып керә йортына,
Кайткач бар да онтыла.
Тик, кадакка эләгеп,
Юбка гына ертыла.

Ул көн «соң» дип ямамый,
Аны-моны карамый.
Иртән китә хезмәткә,
Кичегергә ярамый.

Әле дә кичә соң кайтып,
Йоклаган кырын ятып;
Күрше карчык эшенә
Чак җибәргән уятып.

Менә бара ул, кара!
Юбка гына чайкала.
Исе китеп хатын-кыз
Юбкага карап кала.

Икенче көн ни күрәм? –
Бер елыйм да бер көләм.
Урам тулы хатын-кыз,
Бар да ерык юбкадан.

Күрче, күршем текканче,
«Мода» дип, көн үткәнче,
Бар да ерган юбкасын
Бот төбенә җиткәнче!


Әй, Хәдичә, Хәдичә!
Кичегеп кайтып кичә,
Нинди эшкә чуалдың –
Яңа мода чыгардың.

Кызлар, төнлә йөрмәгез,
Коймадан сикермәгез,
Тагын әллә ни ертып,
«Мода», – дия күрмәгез.

Эрнест ДЫШАЕВ, «Чаян» № 4, 2002



Таһир ФӘИЗОВ, «Чаян» № 18, 1991



– Әтиеңнән үрнәк ал! Үзен яхшы тоткан өчен аны төрмәдән вакытыннан алда чыгаралар!

КАРИКАТУРА МУЗЕЕ БУЛЫРМЫ?

Фейсбукта безнең даими авторыбыз, Екатеринбург карикатура музее директоры Максим Смагинның җан авазы яңгырады.

«Хөрмәтле ханымнар һәм әфәнделәр! Безнең музей соңгы көннәрен яши. Аның киләчәк язмышы билгесез. Кызганыч, мин мөрәҗәгать иткән шәһәр һәм өлкә чиновниклары бу мәсьәләгә тиешенчә игътибар бирә алмадылар. Екатеринбург музейчыларына аның хәзерге структурага мөстәкыйль организм булып керүе кирәк түгел. Әйе, Россиядә беренче булып шундый музей ачканнар; әйе, ике ел эчендә берничә дистә күргәзмә уздырганнар...

Ирексездән сорау туа: Екатеринбургка карикатура музее кирәкме?

Мондый музейлар Лондонда, Варшавада, Австриядәге Кремс шәһәрчегендә, Мехикода, Истанбулда, Израильдәге Холонда, Кубада эшләп килә. Ә Габровода гади музей гына түгел, Юмор һәм Сатира йорты! Ә бездә нәрсә?»

Безнең Казаныбызда ничек соң? Карикатура музее булдыру турындагы фикер күптәннән яшәп килә. Моның өчен бар да бар – Казан карикатура мәктәбенең данлы традицияләре, бай архивы булган «Чаян» журналы, бу эш өчен янып йөрүчеләр, меңләгән туристлар... Бары тик хакимият көченә таянган ихтыяр гына җитми. Бәлки, аны юмор хисеннән мәхрүм булмаган Казан башлыгы Илсур Метшин күрсәтер? Ул чагында инде Татарстан башкаласында тагын бер «туристлар казаны» барлыкка килер иде. Ә, нәрсә? Чәй музее бар, чәкчәкнеке бар, хәтта көмешкә музее өчен дә урын табылган... Ә юмор нәрсәсе белән ким?

Мәркәзебезнең тагын бер бай тарихлы ягын күрсәтергә дә вакыт җиткәндер!


ЧАЯН







Максим СМАГИН рәсемнәре



Вячеслав ШИЛОВ

Кәнүшнә дәфтәре

Конюх Гайфуллага беркөнне көтмәгәндә илһам килде.

Шимбә көнне иртән, кичтәгедән соң баш авыртуы басылмасмы дип, кәнүшнәдә ике айдан артык җыелып яткан тиресне чыгара башлаганда булды бу. Ул кинәт кенә, җанының иң аулак почмакларында яткан яшерен хисләрнең кузгалып, үзләренә чыгу юлы эшли башлавын тойды. Алар, ниндидер илаһи тел байлыгын үзләрендә туплап, әзер рифмаланган юллар формасында абзыйның башында бөтерелә башладылар. Уйчанланып киткән абзыйның, капка янындагы өемгә чираттагы кәсне чыгарып салган саен, күңелендә яңа бер дуртьюллык туа торды.

Үзе өчен һич тә таныш булмаган кичерешләргә чолганган рәвештә Гайфулла, дәртләнеп, тиресне өч сәгать дигәндә чыгарып та бетерде.

Эшне тәмамлагач, янә кәнүшнәгә керде, шактый күтәрелеп киткән кәеф белән атларны барлап чыкты. Ишек янына җитәрәк, никтер, кире борылып, "һайт!" дип кычкырып куйды; һәм, үзе дә сизмәстән, күңеленнән ургып чыккан юлларны укырга кереште. Тирестән арынып, бушап калган корылма эчендә Гайфулланың көр тавышы аеруча тирән моң һәм аһәң белән яңгырый иде.

Иренеп кенә салам чәйнәүче олы яшьләрдәге ике алаша, башта колакларын торгызып алсалар да, бу хикмәткә битараф калдылар. Ә почмакта торган яшь айгырны Гайфулланың шигърияте бик дулкынландырды: ул ал аякларын берничә тапкыр җиргә тибеп алды һәм көчле итеп кешнәп куйды.

...Тирес төяшергә килгән ахирәте Мәрдәншага Гайфи бу гаҗәеп хәл турында берни дә әйтмәде. "Вакыты җиткәч, исе-акылы китәр әле", дип, үзалдына елмаеп кына куйды...

...Кичке Сабантуйга, бала-чагаларын җыеп, бөтен авыл халкы килгән иде. Гайфулла абзый да, туйдан калган ак күлмәгенә ат башы төшерелгән шахмат значогы тагып, тәкәббер генә кыяфәт белән кеше арасында уралып йөрде. Ул ашыкмады: җырланасы җырлар җырланып, уеннар уйналып, исерекләр айнып, халык таралу ягын карый башлагач кына, агач басмага күтәрелде.

– Шигырьләр. Кәнүшнә дәфтәреннән! – Гайфулланың дәртле авазы, кичке һаваны ярып, өскә күтәрелде һәм тирәдәге тупыл очларына барып эленде. Беренче юлларны укыганда ук, бернечә хатынның балаларын җилтерәтеп авыл ягына шылганнарын абайлады. Ләкин илһам диңгезендә йөзүче абзыебыз, күзләрен үк йомып, кулларын өскә күтәреп сөйләвен дәвам итте. Халыкның гүләвендә соклану билгеләре күреп, тавышын тагын да көчәйтә төште, һәм үзенең рухи байлыгын дөньяга сипте...

...Гайфи күзләрен ачып басмадан сикереп төшкәндә, эскәмияләрдә инде беркем дә юк иде диярлек. Дусты Мәрдәнша гына, "вәт матершинник, ә!" дип сөйләнә-сөйләнә, һушыннан язган яшь бер туташның битенә су бөркергә маташа иде. Дөрес, бер-беренә сыенышып, арткы рәттә икеөч пар утыра иде, бугай. Ләкин аларда, ахрысы, шигырь кайгысы юк иде...

ИПИ САЛА ИДЕ ӘНИ...

Таңда әни ипи сала иде,
Кичтән басып куеп камырын.
Иң беренче җылы истәлекләр
Җибәргәндер шуннан тамырын.

...Ипи сала иде әни таңда,
Үзалдына җырлап, моңланып;
Тезә иде әзер кумәчләрен,
Кайнар мичкә җыр һәм моң салып.

Урамнарга бөркеп чыккан исе
Белмим, күпме йортны уяткан –
Ул ислердән исереп, күрше-күлән
Оеткыга керде һәр яктан...

Әнкәй салып, мичтә пешкән икмәк
Һәрчак булды безнең өстәлдә.
Эзәрлекләп йөрде аның исе
Туган йорттан чыгып киткәч тә...

...Йөрәгемнән чыгып, сүзләр тезелә,
Киртәләрен ярып үткәннең.
Каннарымда шулай уйный бугай
Оеткысы моңлы әнкәмнең...





САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 3 (1892) март 2020

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 5.03.2020 ел.
Тираж –1503 Заказ А-447

**Редакциянең адресы: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.**

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Тәҗрибәле һөнәрче яшь һөнәрчедән нәрсәсе белән аерыла?

2. Төньяк халыкларында ризык һәм уңыш алласы, 8 хәреф?

3. Нәрсә ул биокыр?

4. Гырлаудан иң яхшы чара?

5. Армиядә нишләп КВН юк?

6. Нәрсә ул начар абруй?

7. Нәрсә ул җәмәгатьчелек фикере?

ЖАВАПЛАР

1. Яшь һөнәрче эшли белми, ә тәҗрибәлесе – эшләмәскә белә. 2. Вертолёт. 3. Авыл бәдрәфе. 4. Беренче булып йокыга китү. 5. Чөнки шаяннар гауптвахтада утыра, ә тапкырлар – өйләрендә. 6. Башкалар теләгәнчә яши алмау 7. Алардан сорамаган кешеләрнең фикере.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исеме укыгыз. Журналыбызның 2 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **"КАЗАННАРДАН МӘСКӘҮ".**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
Г. ГАРИПОВА (Сарман.),
Н. НӘҖИПОВА (Әлмәт р-ны, Васильевка ав.),
Б. ШӘЙХЕТДИНОВ (Алексеевский р-ны, Урта Тигәнәле ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Чаллыдан **Гали БАҺАВЕТДИНОВ!**

СЕРГЕЙ АНДРИАНОВ



Сергей АНДРИАНОВ үзенең иҗатында карикатура сәнгатендә мөмкин булган бөтен уңай сыйфатларны туплаган дип әйтергә була. Аның рәсемнәре күпкырлы – кабатланмас график стиль дә, үткен темалар да, дөньяга үз карашы да бар...

Тик бу аңа карата булган ихтирамыбызның бердәнбер сәбәбе түгел. Ул безнең белән озак еллар буе хезмәттәшлек итүче тугры авторыбыз. Ә хәзерге катлаулы заманда бу – бик кыйммәтле һәм сирәк очрый торган сыйфат. Шуның өчен дә дөньяга ул «Чаян» өчен килгән карикатурачы, дип, чын мәгънәсендә әйтә алабыз.







4612750670080